РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«16» декабря 2021 г. г. Альметьевск № 58

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетның «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы карары нигезендә,

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында »гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советның 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карар белән расланган Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт ечен түләү тәртибе һәм шартлары турында 2 пунктның 6 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Муниципаль хезмәт вазыйфасына муниципаль хезмәткәр билгеләнгән очракта, ул элек биләгән вазыйфалар төркеменә караганда, муниципаль хезмәт вазыйфаларының югарырак төркеменә караган очракта, биләгән вазыйфа керә торган вазыйфалар төркеме өчен беренче класслы чин бирү өчен аның окладына күләмен исәпләп чыгару вазыйфаи окладка процентлы ставкадан чыгып, 3 процентка тигез итеп башкарыла.

Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасына элек биләгән вазыйфаларның түбәнрәк төркеменә караган һәм элек биләгән вазыйфасы

буенча аңа класс чины бирелгән очракта, класс чины ечен оклад күләмен исәпләү вазыйфаи окладка процентлы ставкадан чыгып, 7 процентка тигез итеп башкарыла;».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация сайтында урнаштырырга.

3. Билгеләргә:

әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә;

әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 4 октябреннән барлыкка килгән хокук менәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов